АГЕНТСТВО
ИНВЕСТИЦИОННОГО РАЗВИТИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ИНВЕСТИЦИОН ҮСЕШ
АГЕНТЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

«16» декабрь 2016 г. № 41

**Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгының 2014 ел 19 маендагы 76/2 лс номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенә вакант урынга урнашу (кадрлар резервына кертү) конкурсы турында»гы боерыгына үзгәреш кертү турында**

2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәте турында» Федераль законга, РФ Президентының 2005 елның 1 февралендәге 112 номерлы «Россия Федерациясенең дәүләт гражданлык хезмәтенә вакант урынга урнашу конкурсы турында»гы указына, Татарстан Республикасының 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте турында»гы законына туры китерү максатыннан

БОЕРАМ:

1. Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгының 2014 елның 19 маендагы 76/2 лс номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенә вакант урынга урнашу (кадрлар резервына кертү) конкурсы турында»гы боерыгына (алга таба – Боерык) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

Боерыкның 2нче Кушымтасындагы 14 пунктны төшереп калдырырга.

2. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче Т.И. Минуллина